# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында" 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 23 сентябрендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 4, № 9 – 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 9; 2003, № 9 (II өлеш); 2005, № 12 (I өлеш); 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 4), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**"Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

1. Татарстан Республикасында түбәндәге эш көне булмаган бәйрәм көннәре билгеләнә:

Татарстан Республикасы көне – 30 август;

Татарстан Республикасы Конституциясе көне – 6 ноябрь;

Ураза бәйрәме;

Корбан бәйрәме.

2. Татарстан Республикасында бәйрәм көне билгеләнә:

Туган тел көне – 26 апрель.

3. Татарстан Республикасында истәлекле дата билгеләнә:

Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көне – 21 май.

4. Ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә Ураза бәйрәмен һәм Корбан бәйрәмен бәйрәм итә башлауга туры килә торган көннәр Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

5. Ял көннәре һәм әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән бәйрәм көннәре туры килгәндә ял көне бәйрәм көненнән соң килүче эш көненә күчерелә.

**2 статья**

1. Татарстан Республикасында язгы кыр эшләре тәмамлану уңаеннан татар халык бәйрәме "Сабан туе" һәм рус халык бәйрәме "Каравон" билгеләп үтелә. Әлеге бәйрәмнәрне уздыру даталары ел саен Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

2. Татарстан Республикасында үзләрен аерым этник берлекләргә кертүче гражданнар бүтән милли бәйрәмнәр уздырырга хокуклы. Аларны уздыру даталары җирлек территориясендә этник төркемнәр тупланып яшәгән урыннарда – җирлек башлыгы тарафыннан, ә берничә җирлек территориясендә тиешле муниципаль район башлыгы тарафыннан билгеләнә. Мондый бәйрәмнәрне бердән артык район территориясендә, шулай ук республика әһәмиятендәге шәһәр территориясендә уздырган очракта карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.

**3 статья**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасының башка бәйрәм көннәре, шулай ук истәлекле даталары да билгеләнергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасының һөнәри бәйрәмнәре көннәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

**4 статья**

Бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталар уңаеннан дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм хезмәт коллективлары инициативасы буенча иҗтимагый-сәяси чаралар уздырыла.

**5 статья**

1. Татарстан Республикасында гражданнар дини бәйрәмнәрне билгеләп үтәргә хокуклы.

2. Конфессияләр вәкилләренә аларның дини бәйрәме көнендә милек рәвешләренә һәм эшчәнлек өлкәсенә бәйсез рәвештә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар администрациясе тарафыннан конфессияләр

вәкилләре үтенече буенча еллык отпуск исәбенә йә, хезмәткәрләр белән килешеп, башка шартларда ял көне бирелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 74-ТРЗ